ҖОМГА
5
МАРТ
1943 ел.
№ 52 (6774)
Аерым номеры 20 тиен.

ВАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) ның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ ҺӘМ КАЗАН ШӘҺӘР КОМИТЕТЛАРЫ, ТАССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ҺӘМ ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ КАЗАН ШӘҺӘР СОВЕТЫ ОРГАНЫ.

ХАЛЫКАРА КОММУНИСТИК ХАТЫН-КЫЗЛАР КӨНЕ— 8 НЧЕ МАРТ ТУРЫНДА

ВКП(б) ҮЗӘК КОМИТЕТЫ КАРАРЫ

Быел совет хатын-кызлары Халыкара коммунистик хатын-кызлар көнен Гитлер Германиясенә һәм аның ялчыларына каршы ватан сугышының хәлиткеч моментында каршылыйлар. Өч айдан артык инде безнең гаскәрләрнең уңышлы һөҗүме дәвам итә. Верховный Баш Командующий иптәш Сталин җитәкчелегендә Кызыл Армия немец-фашист гаскәрләргә күп кенә җимергеч ударлар ясады һәм дошманны җиңү өчен ныклы нигез салды. Уннарча шәһәрләр һәм күп меңнәрчә авыллар немец басып алучылардан азат ителде. Дошманны совет җиреннән массовый төстә куу башланды.

Ватан сугышында совет хатын-кызлары немец-фашист ерткычларга каршы актив көрәшүчеләр сафларында торалар. Бөтен үткән тарихта беркайчан да әле хатын-кызлар үз ватаннарын саклауда хәзерге кебек, халкыбызның бөек азатлык сугышындагы кебек, шундый үз-үзләрен аямыйча катнашканнары юк иде.

Совет хатын-кызларының саклар-лык уңышлары бар!

Совет власте хезмәт иясе хатын-кызларга тормышның барлык өлкәләрендә тулы һәм чын тигез хокуклылык китерде. Ул, хатын-кызларны дәүләтне идарә итүдә катнашуга тартты, иркле иҗат хезмәте өчен һәм бәхетле ана булу өчен барлык шартларны тудырды.

Немец-фашист юлбасарлар халкыбызның тормышына, азатлыгына һәм бәйсезлегенә, хезмәт иясе хатын-кызларның барлык тарихи казанышларына куркыныч тудыралар. Вакытлыча басып алынган совет районнарында гитлерчылар колак ишетмәгән җинаятьләр эшлиләр, гражданнар халкын кыралар, хатын-кызларны көчлиләр, балаларны газаплыйлар һәм үтерәләр. Фашист кол итүчеләр йөз меңнәрчә совет хатын-кызларын Германиягә авыр каторга эшләренә куып алып киттеләр.

Илебездәге хезмәт иясе хатын-кызларның йөрәкләре немец-фашист басып алучыларга карата дәһшәтле ачу һәм бөек нәфрәт белән тулган. Алар, бөтен халык белән бергәләп, үз ватаннарының азатлыгын һәм бәйсезлеген кабахәт дошманнан саклау өчен күтәрелделәр. Тылда һәм фронтта совет патриоткалары геройлык үрнәкләре һәм ватаныбызга, большевиклар партиясенә, иптәш Сталинга чын күңелдән бирелгәнлек үрнәкләре күрсәтәләр.

Ватан сугышы вакытында җәмәгать производствосында хатын-кызларның роле үлчәүсез үсте. Фабрикаларда һәм заводларда, колхозларда һәм совхозларда эшләүче миллионнарча хатын-кызлар, үз-үзләрен аямыйча эшләп, фронтка коралларны, сугыш припасларын һәм азыкны тоткарсыз җитештерүне тәэмин итәләр. Меңнәрчә хатын-кызлар заводларга, фабрикаларга, учреждениеләргә җитәкчелек итәләр. Йөз меңнәрчә хатын-кызлар, катлаулы профессияләрне үзләштереп, фронтка киткән ирләрне алыштырдылар. Авыл хуҗалыгында хатын-кызларның роле аеруча үсте. Хәзер колхоз производствосының төп авырлыгы колхозчы хатын-кызлар җилкәсенә төште. Ун меңнәрчә хатын-кызлар колхозларга җитәкчелек итәләр, бригадир, звено җитәкчесе, терлекчелек фермасы мөдире һәм агроном булып эшлиләр.

Батыр Кызыл Армиябез сафларында һәм партизаннар отрядларында совет хатын-кызлары, үз-үзләрен аямыйча, немец басып алучыларга каршы көрәшәләр, санитарка, медсестра, врач, элемтәче, снайпер хезмәтләрен, һава һөҗүменнән саклану частьларында хезмәтне намус белән алып баралар. Командованиенең хәрби заданиеләрен үрнәк булырлык итеп үтәгән өчен һәм шул вакытта батырлык һәм геройлык күрсәткән өчен күп кенә данлыклы совет хатын-кызларына Советлар Союзы Герое дигән бөек исем бирелде. Бөек азатлык сугышында катнашучы меңнәрчә хатын-кызлар кыюлык һәм батырлык өчен Советлар Союзы орденнары һәм медальләре белән бүләкләнделәр. Совет хатын-кызлары яралыларга игътибар бирәләр һәм алар турында кайгырталар, Кызыл Армия өчен бүләкләр һәм җылы киемнәр җыюны оештыралар, самолетлар һәм танклар төзелешенә средстволар җыюда актив катнашалар, фронтовиклар семьялары турында аналарча кайгыртучанлык күрсәтәләр, ятим калган балаларны үз семьяларына тәрбиягә алалар. Ун меңнәрчә совет хатын-кызлары, яралы сугышчыларның тормышын саклап калу өчен, үзләренең каннарын бирәләр.

ВКП(б) Үзәк Комитеты партиянең барлык оешмаларына, халыкара хатын-кызлар көнен—8 нче мартны киң массовый-политик кампания итеп үткәрергә тәкъдим итә.

Ватан сугышының хәзерге хәлиткеч моментында совет халкыннан һәм совет хатын-кызларыннан, дошманны тар-мар итү өчен, барлык көчләрне тагын да күбрәк бирү таләп ителә. Кызыл Армия һөҗүм сугышлары алып баруны, немецларны совет җиреннән куууны дәвам иттерә. Ләкин дошман көчле әле, ул ярсынып каршылык күрсәтә. Гитлер Германиясенә каршы көрәш әле вакыт таләп итә, корбаннар таләп итә, көчләребезне җигүне һәм барлык мөмкинлекләребезне туплауны таләп итә.

Хатын-кызлар хезмәтенең барлык резервларын тулысынча тупларга кирәк. Үз-үзеңне аямыйча эшләү— һәрбер совет хатын-кызының изге бурычы. Хатын-кызларны производствога өйрәтүне һәм алдынгы эшче һәм колхозчы хатын-кызларны җитәкчелек эшенә күтәрүне тагын да киңрәк җәелдерергә кирәк. Партия, совет, профсоюз һәм комсомол оешмалары җәмәгать производствосында эшләүче хатын-кызларның көнкүреш ихтыяҗлары турында һәръяклап кайгыртырга тиешләр, чөнки хатын-кызларны производствога тагын да тартуның уңышлы чыгуы һәм аларның хезмәт җитештерүчәнлеге шуңа бәйләнгән. Партия, комсомол һәм профсоюз оешмалары хатын-кызларны, бигрәк тә производствога яңа килгәннәрне, политик яктан тәрбияләүгә иң җидди игътибар бирергә тиешләр.

Эшче, инженер һәм техник хатын-кызлар! Һөҗүм итүче Кызыл Армиягә танкларны, самолетларны, орудиеләрне, пулеметларны, винтовкаларны, сугыш припасларын, киемнәрне тагын да күбрәк бирегез! Металл коюны, күмер чыгаруны, электр энергиясе җитештерүне арттырыгыз. Үз эшегезнең техникасын бик яхшы итеп үзләштерегез һәм хезмәт җитештерүчәнлеген туктаусыз күтәрегез.

Тимер юлчы хатын-кызлар! Фронт өчен кораллар, сугыш припаслары һәм азык төялгән поездларны тизрәк үткәрегез. Немец-фашист басып алучыларны тар-мар итүдә Кызыл Армиягә булышлык итегез! Тимер юлларның тоткарсыз һәм төгәл эшләүләре өчен көрәшегез! Тимер юл транспорты техникасын үзләштерегез!

Колхозчы хатын-кызлар, МТС һәм совхозларның эшче хатын-кызлары! Хәзер Кызыл Армияне һәм тылны азык белән тәэмин итү сезнең басуларда ничек эшләвегезгә бәйләнгән. Хәзер сез язгы чәчүнең уңышлы чыгуын хәл итәсез. 1943 нче елны югары иген уңышы алуны тәэмин итегез. Бөтенесе фронт өчен, бөтенесе җиңү өчен!

Элемтәче, снайпер хатын-кызлар һәм ватан сугышында катнашучы барлык хатын-кызлар! Сугыш эшенә өйрәнүне туктаусыз яхшыртыгыз! Кызыл Армиядә элемтә эшен һәръяклап яхшыртыгыз, төз атарга өйрәнегез! Барлык гаскәрләрнең һөҗүме уңышлы баруга барлык көчләрегез белән булышлык итегез! Гитлерчы басып алучыларны рәхимсезлек белән кырыгыз!

Санитарка, медсестра һәм врач хатын-кызлар! Алгы позицияләрдә яралыларга кичекмәстән ярдәм итегез, яраланган сугышчыларны һәм командирларны, кораллары белән бергә, сугыш кырыннан алып чыгыгыз, госпитальләрдә дәваланучы сугышчыларга һәм командирларга игътибар бирегез һәм алар турында кайгыртыгыз! Исегездә тотыгыз, яраланган совет сугышчыларының тормышы һәм стройга кайтуы сезнең эшегезгә бәйләнгән!

Хатыннар һәм кызлар! Хәрби белгечлекләрне бик яхшы итеп үзләштерегез! Төз атарга өйрәнегез. Һава һәм химия һөҗүменнән саклану эшен, санитария эшен, элемтәне өйрәнегез. Яралыларны тәрбияләүне тәэмин итегез, фронтовиклар семьялары турында аналарча кайгыртучанлык күрсәтегез! Ятим балалар турында кайгыртуны үз өстегезгә алыгыз—бер генә ятим бала да ана иркәләвеннән мәхрум булмасын.

Немец оккупантлардан азат ителгән шәһәрләрдәге һәм авыллардагы хатын-кызлар! Промышленностьны, авыл хуҗалыгын, мәктәпләрне, көтепханәләрне, больницаларны һәм пекарняларны тизрәк аякка бастырыгыз. Шәһәрләрдә һәм авылларда нормаль тормышны юлга салыгыз!

Вакытлыча дошман тарафыннан басып алынган совет районнарындагы хатын-кызлар! Сезнең азат булуыгыз сәгате якынлаша! Гитлерчы кабахәтләрне рәхимсезлек белән кыруда партизан отрядларына булышлык итегез, чигенүче дошманга шәһәрләребезне һәм авылларыбызны яндырырга ирек бирмәгез!

Партизан хатын-кызлар! Һөҗүм итүче Кызыл Армиягә бөтен көчегез һәм барлык средстволарыгыз белән булышлык итегез! Дошман тылында партизаннар көрәше ялкынын киңрәк кабызыгыз! Партизан отрядларының хәрби заданиеләрен үз-үзегезне аямыйча үтәгез! Дошман гаскәрләрен ташуны, кораллар һәм сугыш припаслары китерүне өзегез, дошманның хәрби складларына ут төртегез! Хәрби эшне туктаусыз өйрәнегез! Немец басып алучыларны һәрбер адымда эзәрләгез һәм юк итегез!

ВКП(б) Үзәк Комитеты Халыкара коммунистик хатын-кызлар көнендә, эшче, колхозчы хатын-кызларны, интеллигенция хезмәте хатын-кызларын, санитаркаларны, медсестраларны, врач һәм элемтәче хатын-кызларны, данлыклы партизанкаларны, Советлар Союзының барлык хезмәт иясе хатын-кызларын котлый һәм ватан сугышының хәлиткеч моментында совет хатын-кызларының үзләренең барлык көчләрен немец басып алучыларны тәмам тар-мар итү эшенә бирәчәкләренә ныклы ышаныч белдерә.

Бөтенсоюз Коммунистлар (большевиклар) Партиясе Үзәк Комитеты.

РЖЕВ БЕЗНЕКЕ

ХӘРӘКӘТТӘГЕ АРМИЯ, 3 март: (ТАСС ның махсус хәбәрчесеннән). Бүген, озак дәвам иткән бик каты сугыштан соң, совет гаскәрләре Ржев шәһәрен алдылар.

Үткән елны ук инде немецлар, Ржев плацдармына гаять зур әһәмият биреп, шәһәрне һәм аңа килү юлларын көчле итеп ныгытылган районга әйләндергәннәр. Шәһәр чикләре берничә рәт тимер чыбык киртәләре белән әйләндереп алынган, киртәләрнең эчке ягында озак вакытка ясалган бик күп ут ноктачалары булган. Ржевка килү юлларына эре калибрлы пулеметлардан һәм автоматлардан, сынау өчен, алдан ук көчле ут белән атып караган булганнар. Шуның өстенә фашистлар гарнизоны шәһәрнең үзендә дә ныгытмалар ясаган: урамнарга һәм мәйданнарга баррикадалар корган, үтеп йөри торган юлларга миналар куйган, күп йортларда һәм урам чатларында ДЗОТлар ясаган.

Моннан берничә көн элек безнең гаскәрләр Ржевка каршы кискен штурм башладылар. Совет подразделениеләренең беренче группасы шәһәрдән көньяк-көнчыгыштарак дошман оборонасын өзде һәм, һөҗүм хәрәкәтләрен дәвам иттереп, Волгага караган зур территорияне дошманнан чистартты. Озак та үтми безнең подразделениеләр көнчыгыштан һәм көньяктан шәһәргә якын ук килделәр. Шул ук вакытта гаскәрләрнең икенче группасы Ржевтан көнбатыштарак һөҗүм алып барды һәм киң фронт белән Волганы кичте. Уң флангтагы подразделениеләр Ржев—Великие Луки тимер юлына чыктылар. Совет гаскәрләренең бу группировкасының сул канаты, шәһәрне көнбатыштан аерып, аны тылдан чолгап ала башлады.

Шәһәр дошманнан бөтенләй чистартылды.

Шәһәрдә һәм аңа килү юлларында 2.000 гә якын дошман солдатлары һәм офицерлары үтерелде. Кызыл Армия частьлары бик күп трофейлар кулга төшерделәр.

Е. КАПЛАНСКИЙ.

Совет Информбюросыннан

3 нче МАРТТАГЫ ИРТӘНГЕ БЕЛДЕРҮ

3 нче мартка каршы төндә безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә һөҗүм сугышлары алып бардылар.

* * *

Ростов-Доннан көнбатыштарак безнең гаскәрләр һөҗүм сугышлары алып бардылар. Н-че часть, дошман окопларына бәреп кереп, 100 гә якын немец солдатларын һәм офицерларын кырды. Икенче бер участокта гитлерчылар кичә безнең частьлар алган бер биеклекне яңадан кайтарып алырга маташып карадылар. Гвардияче кече лейтенант Фатин командалыгындагы подразделениенең сугышчылары дошманның контратакасын кире кайтардылар һәм аның 60 солдатын һәм офицерын кырып ташладылар.

* * *

Ворошиловградтан көньяк - көнбатыштарак Н-че часть сугышчылары халык яши торган бер пункт өчен булган сугышта дошманның ике рота пехотасын тар-мар иттеләр, 3 танкысын зарарладылар һәм яндырдылар, сугыш припаслары төялгән 7 автомашинасын юк иттеләр. Трофейлар кулга төшерелде.

* * *

Харьковтан көнбатыштарак Н-че берләшмә частьлары халык яши торган берничә пунктны алдылар. Урам сугышларында 300 гә якын дошман солдатлары һәм офицерлары юк ителде. 2 сугыш припаслары складьы һәм бер азык складьы кулга төшерелде. Безнең танкистлар, алга таба барып, немецларның моторлаштырылган пехота колоннасын таркаттылар һәм бер өлешен юк иттеләр. Дошманның 14 автомашинасы һәм ягулык тутырылган 2 автоцистернасы юк ителде.

* * *

Курскидан көнбатыштарак Н-че часть подразделениеләре, омтылышлы атака нәтиҗәсендә, немецларны халык яши торган ике пункттан бәреп чыгардылар. 2 орудие, 100 дән артык винтовка, сугыш припаслары һәм төрле сугыш милекләре кулга төшерелде. Икенче бер участокта безнең сугышчылар дошманның контратакасын кире кайтардылар һәм 100 гә якын гитлерчыны юк иттеләр. 2 танк, танкка каршы ата торган 3 орудие һәм 12 пулемет кулга төшерелде.

* * *

Кубаньда безнең гаскәрләр һөҗүм операцияләрен дәвам иттерделәр. Н-че часть подразделениеләре, төнге сугышта дошманның тылына барып чыгып, бер ротага якын немец пехотасын кырдылар. Безнең артиллериябез уты белән дошманның 3 танкысы сафтан чыгарылды һәм бер сугыш припаслары складьы шартлатылды.

* * *

Кырым партизаннарының бер отряды февраль ахырында немецларның бер хәрби эшелонын юлдан чыгарган. Бер паровоз, сугыш йөкләре төялгән 7 платформа һәм 5 вагон җимерелгән. 100 гә якын гитлерчы үтерелгән.

* * *

Ростов партизаннарының бер группасы немецлар часте урнашкан бер авылга бәреп кергән. Совет патриотлары, часовойларны тын гына үтереп, штаб бинасына гранаталар ыргытканнар. 3 немец офицеры һәм 15 солдат үтерелгән.

* * *

Немецларның 320 нче гренадер дивизиясенең 585 нче полкындагы 1 нче батальонның плен алынган командиры капитан Вилли Курт болай диде: «320 нче дивизия 1942 нче елны бөтен ел буена Франциядә, Шербур районында торды. Анда ул диңгез ярын саклау хезмәтен алып барды. Үткән елның 27 нче декабрендә дивизия Россиягә китте. Франциядә чакта хәтта офицерлар да көнчыгыш фронттагы чын хәлне аз беләләр иде. Китәргә аз гына калганда мин полк командиры подполковник Фостта командованиенең рәсми бюллетенен күрдем. Анда немец гаскәрләренең Сталинградны тулысынча алганлыклары әйтелгән иде. Мин немецлар командованиесенең бу белдерүен чынга алдым һәм иң соңгы вакытларга кадәр бу сугышта Германия җиңәчәк дип ышанып килдем. Россиядә, сугыш кырында минем бу ышанычым какшады. Хәзер инде мин бик күңелсез настроениедә һәм, инде Германия җиңә алмый дип уйлыйм. Фронтка барганда юлда мин итальян гаскәрләренең тәртипсез рәвештә чигенүче калдыкларын күрдем. Мин ачыктан-ачык әйтәм: әгәр дә Италия дивизияләренең Россиядә коточкыч язмышка очраганлыкларын Италиядә белсәләр иде, ул чагында бер генә итальян да, ул солдат булса да, офицер булса да, моннан соң беркайчан да кулына корал тотып Россия җиренә аяк басарга батырчылык итмәс иде. Безнең дивизия дә шулай ук авыр югалтуларга дучар ителде. Русларның танклары безнең тылга төштеләр. Без ашыгыч рәвештә чигендек. Руслар безнең частьларның чигенүен каплап торучы арттагы сафларны тар-мар иттеләр. Бер сугышта гына да минем батальоннан 287 кеше үтерелде, яраланды һәм өшеде».

* * *

Немец-фашист кабахәтләр Орел өлкәсенең Хорошее авылын бөтенләй эштән чыгарганнар. Бандитлар барлык колхоз активистларын һәм күп кенә гади колхозчыларны юк иткәннәр. Немецлар авыл советы председателен бик озак эзләп йөргәннәр, ләкин крестьяннар аны фашистлардан яшергәннәр. Моны белгәннән соң гитлерчылар колхозчылардан Шкаликовны һәм Дубинкинны асып үтергәннәр, ә өч колхозчыны атканнар. Оккупация вакытында барлыгы 150 кеше атып үтерелгән. Немец-фашист басып алучылар чигенгән чакта 14 яшьтән 50 яшькә кадәр булган, исән калган барлык ирләрне ирексезләп үзләре белән алып киткәннәр.

3 нче МАРТТАГЫ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

3 нче мартта безнең гаскәрләр, озак дәвам иткән бик каты сугыштан соң, **Ржев** шәһәрен алдылар.

Каты сугышлардан соң безнең гаскәрләр **Льгов** шәһәрен һәм тимер юл үзелын һәм **Дмитриев-Льговский** шәһәрен алдылар.

Фронтның башка участокларында безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә һөҗүм сугышлары алып бардылар.

* * *

2 нче мартта безнең авиация частьлары фронтның төрле участокларында дошманның гаскәрләр һәм йөкләр төялгән 100 гә якын автомашинасын юк иттеләр яки зарарладылар, 14 артиллерия батареясының утын бастырдылар.

* * *

1941 нче елның октябрендә немец-фашист гаскәрләр Ржевны алганнан соң аны һәм аңа килә торган юлларны көчле итеп ныгытылган районга әйләндергәннәр. Күп айлар буена дошман, гаять зур югалтулар белән хисаплашып тормастан, шәһәрне үз кулында тотып калырга омтылды. Моннан берничә көннәр элек безнең гаскәрләр, Ржевны көньяк-көнбатыштан һәм көньяк-көнчыгыштан әйләнеп үтеп, кискен штурм башладылар һәм бүген Ржев шәһәрен тулысынча алдылар. Ржевка килү юлларында һәм аның урамнарында немец солдатларының һәм офицерларының 2.000 гә якын үле гәүдәләре табылды. Безнең гаскәрләр 112 танк, 78 орудие, 35 паровоз, 1.200 вагон, 5 склад, күп кенә снарядлар, миналар, пулеметлар, винтовкалар һәм төрле сугыш милекләре кулга төшерделәр.

* * *

Ворошиловградтан көньяк-көнбатыштарак Н-че часть дошманга каршы сугышта 300 гә якын немец солдатларын һәм офицерларын юк итте. 2 орудие, 11 пулемет, 3 миномет, снарядлар һәм миналар төялгән 10 автомашина кулга төшерелде. Икенче бер участокта безнең гвардияче минометчикларыбызның ут һөҗүмнәре белән дошманның бер сугыш припаслары складьы шартлатылды һәм җыелып тора торган пехотасы таркатылды.

* * *

Харьковтан көнбатыштарак безнең гаскәрләр һөҗүм сугышлары алып бардылар. Н-че часть сугышчылары сугыша-сугыша алга киттеләр һәм халык яши торган 3 пунктны алдылар. 400 дән артык гитлерчы юк ителде. Немецларның 7 танкысы зарарланды һәм яндырылды. Трофейлар кулга төшерелде һәм пленныйлар алынды. Икенче бер участокта безнең танкистлар дошманның бер рота пехотасын тар-мар иттеләр һәм 4 орудие, 13 пулемет кулга төшерделәр.

* * *

Каты сугышлардан соң безнең гаскәрләр Льгов шәһәрен һәм тимер юл узелын алдылар. Бүгенге көн эчендә генә дә шәһәрнең урамнарында 800 немец солдаты һәм офицеры кырып ташланды. Бик күп трофейлар кулга төшерелде. Шулар арасында 148 вагон снаряд, шуның өстенә тагын бик күп снаряд штабельләре, 22 вагон порох, 3 сугыш припаслары складьы, инженерлык милекләре тутырылган бер склад бар. Трофейларның санын алу дәвам итә.

* * *

Кубаньда Н-че берләшмә соңгы көннәрдә булган сугышларда дошманның 7 орудиесен, 9 минометын, 18 станоклы һәм зенит пулеметларын юк итте. Безнең сугышчылар трофейлар кулга төшерделәр. Шулар арасында 6 паровоз, 28 вагон, 5 орудие, 9 пулемет, 138 автомашина һәм бер радиостанция бар.

* * *

Төньяк-көнбатыш фронтта безнең гаскәрләр һөҗүмне дәвам иттерделәр. Н-че часть халык яши торган берничә пунктны дошманнан чистартты һәм шул вакытта 200 гитлерчыны юк итте. Икенче бер участокта безнең сугышчылар, алга таба барып, трофейлар кулга төшерделәр һәм пленныйлар алдылар.

* * *

Украина партизаннарының бер отряды февраль ахырында бик каты сугышта немецларның 295 нче аерым сапер батальонын тар-мар иткән. 300 дән артык дошман солдатлары һәм офицерлары кырып ташланган. Икенче бер районда Украина партизаннары 25 нче февральгә каршы төндә Германиядән фронтка танклар төялгән бер хәрби эшелон үтеп китәчәкне белеп алганнар. Партизаннар берничә урында тимер юлга миналар куйганнар. Немецлар эшелоны шул миналарга бәрелеп шартлаган һәм тимер юлдан авып төшкән. Бер паровоз һәм танклар төялгән 25 вагон җимерелгән.

* * *

Немецларның 376 нчы пехота дивизиясенең Сталинград янында плен алынган командиры генерал-лейтенант Александр фон Даниэль болай диде: «Дивизия Россиягә килгәндә аның 17.000 кешесе бар иде. Ноябрь сугышларында без гаять күп кешеләребезне һәм техникабызны югалттык. Чигенгән чакта бөтен артиллериянең яртысын диярлек ташлап калдырырга туры килде. Чолганыш боҗрасы бик нык кысылганда инде дивизиядә 12.000 чамасы кеше калды. Без фронттагы гомуми хәлне белмәдек, һәм барыбыз да диярлек читтән ярдәм килүгә өметләнеп тордык. Безгә ярдәмгә килүче Манштейнның җиңелүе бик авыр тәэсир ясады. 10 нчы январьдан соң инде мин бөтенесе беткәнлекне аңладым.

Немец гаскәрләренә Сталинградны кыш буена кулдан ычкындырмау бурычы куелган иде. Командованиенең шуннан соңгы планнары барысы да шуңа корылган иде. Русларның һөҗүме нәтиҗәсендә бу планнар барысы да җимерелде. Немецларның 6 нчы армиясен чолгап алу һәм бетерү операциясе иң оста стратегия булып чыкты. Сталинград янында немец гаскәрләренең җиңелүе сугышның алдагы барышына зур тәэсир ясаячак. 6 нчы армиянең һәлакәте нәтиҗәсендә Германиянең коралы көчләре югалткан гаять күп кешеләрне, техниканы һәм материалларны яңадан тулыландыру өчен бик күп тырышлык һәм вакыт кирәк булачак».

* * *

Харьков өлкәсе, Волчанск шәһәрендә немец басып алучылар 8 ай буена хуҗа булып тордылар. Шул вакыт эчендә немец-фашист кабахәтләр гражданнар халкыннан йөзләрчә кешеләрне кырганнар. Гитлерчы палачлар 5 группа заложникларны— барлыгы 438 кешене атканнар. Шуның өстенә алар шәһәр гражданнарыннан 100 дән артык кешене үтергәнче газаплаганнар. Волчанскидан чигенер алдыннан фашистлар педагогия училищесын, агротехника мәктәбен, Шевченко исемендәге мәктәпне, Пушкин исемендәге мәктәпне, балаларның техника станциясен һәм башка җәмәгать биналарын яндырганнар.

ХӘРӘКӘТТӘГЕ АРМИЯ. Рәсемдә. Н-че частьның чаңгычы-разведчиклары төнге маршта.

ТАСС фотохроникасы.



Ленин ордены һәм Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнгән, Сталин исемендәге артиллерия заводының строгальщигы иптәш Ф. А. Шабаловның бер тәкъдиме бер детальне эшләүдә хезмәт житештерүчәнлеген сигез тапкыр арттырды. Рәсемдә: Ф. А. Шабалов һәм аның өйрәнчеге А. М. Кукин иптәшләр.

ТАСС фотохроникасы.

БЕРЕНЧЕ МАЙ АЛДЫ ЯРЫШЫН ҖӘЕЛДЕРИК!

СУГЫШЧАН ВАХТА ДӘВАМ ИТӘ

Иптәш Сталинның приказына җавап итеп, Н-че заводның уннарча эшчеләре сугышчан стахановчы вахтага басканнар иде. Транспорт бүлегендә шоферлардан Рабигин һәм Киреев иптәшләр, стахановчы вахтага басып, заводның мөһим участокларыннан берсендә һәркөнне 2—3 норма бирел эшлиләр. Цехком председателе иптәш Бобикин булган цехта стахановчы вахтага Савченко, Гыйльмиев, Евстафьева, Салаватуллина, Салихова һәм башка иптәшләрнең бригадалары бастылар. Бу бригадалар барысы да көнлек эшләп чыгару нормасын арттырып үтәп баралар.

Заводта 1 нче Май алды ярышы башланып китте. Сугышчан вахта дәвам итә.

Мишәбаш урман пунктында

Мишәбаш урман пункты (начальнигы иптәш Бәдриев) сезонга бирелгән планны урман кисү буенча 161 процент, ташу буенча 140 процент итеп срогыннан ай ярым элек үтәп чыкты. Верховный Баш Командующий иптәш Сталин приказын өйрәнгәннән соң, пункт эшчеләре шушы елның 15 нче мартына кадәр планнан тыш өстәмә рәвештә 5.000 кубометр утын кисү һәм 2.000 кубометр утын ташу турында яңа йөкләмә алдылар.

1 нче Май алды ярышына кушылып, утын әзерләүчеләр һәм ташучылар сталинчыл вахтага бастылар. Урман кисүчеләрдән Нәҗип Галиев һәм Евдоким Егоров иптәшләр бер көнне 2,25 фисметр урынына 11 фисметр кисеп смена нормасын 450 процентка үтәделәр. Утын ташучылардан К. Галиев, И. Сафин һәм И. Мөбарәков иптәшләр норманы системалы рәвештә 200-220 процент итеп үтәп баралар.

СТАХАНОВЧЫ ШАЛГАНОВА

Менә 8 ай инде заводның почет тактасында стахановчы шлифовщица Шалганованың портреты эленеп тора. Ул эшли торган группаның мастеры иптәш Филиппов аның турында болай ди:

— Шалганова тигез һәм төгәл эшли. Яхшы сыйфатлы продукция бирә. Планын 200 процентка үтәп бара.

Детальләр шлифовкалаганда гаять дәрәҗәдә төгәллек таләп ителә. Бу эштә хезмәт җитештерүчәнлеген ике тапкырга арттыру—зур сәнгать ул. Цехтагы күп кенә кешеләр ул сәнгатьне үзләштерергә телиләр, ләкин бик азлары гына аңа ирешә алалар.

— Мин сынап карыйм әле,—диде Шалганова һәм эшкә кереште.

Бигеле, аеруча ныклыкны һәм игътибарлылыкны таләп итә торган бу төгәл эшне үзләштерү җиңел булмады. Шалганова аның өчен бик күп тырышлык куйды. Уйлаган нәрсәне, һичшиксез, эшләргә дигән омтылыш аңа шлифовка эшен үзләштерергә мөмкинлек бирде.

Иптәш Шалганованың ике абыйсы фронтта. Абыйлары аңа хат язганда еш кына:—ничек эшлисең, сеңел, фронтка ничек ярдәм итәсең? — дип сорыйлар. Һәм ул аларга конкрет җавап бирә:— Мин хәзер шлифовщица, стахановчы, ике-йөз процентчы,—ди.

А. ИГОРЕВ.

СОҢГЫ СӘГАТЬТӘ

I. Безнең гаскәрләр Ржев шәһәрен алдылар

Моннан берничә көн элек безнең гаскәрләр РЖЕВ шәһәренә каршы кискен штурм башладылар. Немецлар шәһәрне һәм аңа килү юлларын күптән инде көчле итеп ныгытылган районга әйләндергән булганнар. Бүген, 3 нче мартта, озакка сузылган бик каты сугыштан соң безнең гаскәрләр РЖЕВНЫ алдылар.

Тулы булмаган саннарга караганда, түбәндәге трофейлар КУЛГА ТӨШЕРЕЛДЕ: танклар—112, төрле калибрдагы орудиеләр—78, паровозлар—35, вагоннар—1.200, төрле складлар—5, шулай ук бик күп снарядлар, миналар, пулеметлар, винтовкалар һәм башка төрле сугыш милекләре.

Шәһәргә килү юлларында һәм Ржевның үзендә дошман 2.000 гә якын үтерелгән солдатларын һәм офицерларын калдырды.

Шәһәргә беренче булып генерал-майор иптәш А. Ф. КУПРИЯНОВ, генерал-майор иптәш Н. Н. ОЛЕШЕВ һәм полковник иптәш В. П. ШУЛЬГА частьлары бәреп керде.

II. Безнең гаскәрләр Льгов һәм Дмитриев-Льговский шәһәрләрен алдылар

Каты сугышлардан соң безнең гаскәрләр ЛЬГОВ шәһәрен һәм тимер юл узелын алдылар. Бик күп трофейлар кулга төшерелде. Шулар арасында 148 вагон снаряд, 22 вагон дары, 3 сугыш припаслары склады һәм аерым рәвештә бик күп снаряд штабельләре, инженерлык милекләре тутырылган 2 склад бар.

Кискен атакадан соң безнең гаскәрләр ДМИТРИЕВ-ЛЬГОВСКИЙ шәһәрен алдылар. Трофейлар кулга төшерелде. Аларның саны алына.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫ.

Безнең гаскәрләр Оленино, Севск, Суджа шәһәрләрен һәм Чертолино станциясен алдылар

1) 4 нче мартта РЖЕВТАН көнбатыштарак безнең гаскәрләр, һөҗүмне җәелдерүне дәвам итереп, ОЛЕНИНО шәһәрен һәм тимер юл станциясен, шулай ук зур тимер юл станциясе ЧЕРТОЛИНОНЫ алдылар. МОСКВА—РЖЕВ—ВЕЛИКИЕ ЛУКИ тимер юлы бөтен буенча дошманнан чистартылды.

2) Орел өлкәсендә безнең гаскәрләр, каты сугыштан соң, СЕВСК шәһәрен алдылар.

3) Курск өлкәсендә безнең гаскәрләр, кискен атака нәтиҗәсендә, СУДЖА шәһәрен һәм тимер юл станциясен алдылар.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫ.

1943 нче ЕЛГЫ ЯЗГЫ ЧӘЧҮГӘ ӘЗЕРЛЕК БУЕНЧА ФРОНТ АЙЛЫГЫ ҮТКӘРҮ ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН АССР ХАЛЫК КОМИССАРЛАРЫ СОВЕТЫ ҺӘМ ВКП(б) ӨЛКӘ КОМИТЕТЫ КАРАРЫ

4 нче март 1943 нче ел

Татарстан АССР Халык Комиссарлары Советы һәм ВКП(б) Өлкә Комитеты карар бирәләр:

1. 1943 нче елгы язгы чәчүгә әзерлек буенча фронт айлыгы үткәрү турында Апас районы, «Яңа ил» авыл хуҗалыгы артеле колхозчыларының һәм колхозчы хатын-кызларының тәкъдимен яхшы дип табарга. Айлыкны 5 нче марттан 5 нче апрельгә кадәр үткәрергә.

2. Район советлары башкарма комитетларының председательләрен, ВКП(б) райкомнарының секретарьларын, МТС ларның һәм совхозларның директорларын һәм политбүлек начальникларын,—«Яңа ил» колхозының мөрәҗәгатен колхозчылар арасында, МТС һәм совхоз эшчеләре арасында киң күләмдә тикшерергә, һәрбер колхоз, МТС һәм совхоз буенча СССР Совнаркомының һәм ВКП(б) Үзәк Комитетының шушы ел 27 нче февраль карары нигезендә, шулай ук ВКП(б) Өлкә Комитетының IX нчы пленумы карарлары нигезендә конкрет чаралар билгеләргә һәм чәчүгә үрнәк булырлык төстә әзерләнүне тәэмин итәргә мәҗбүр итәргә.

Фронт айлыгының төп бурычлары итеп түбәндәгеләрне билгеләргә: СССР Совнаркомының һәм ВКП(б) Үзәк Комитетының 1942 нче ел 12 нче июль карарына төгәл туры китереп, һәрбер колхозны һәм совхозны бөтен сабан басуына җитәрлек чәчүлек орлыклар белән тәэмин итү, орлыкларны чистарту, сортлау һәм контроль-орлыкчылык лабораторияләреннән үткәрү, тракторларга, тагылма һәм атка җигелә торган инвентарьга ремонтны төгәлләү, механизаторлар һәм массовый колхоз кадрлары әзерләү, массовый кышкы агротехника чаралары планын бер сүзсез үтәү, атларны әзерләү, кирәк кадәр санда мөгезле эре терлекләрне эшкә өйрәтү, производство һәм эш планнары төзү.

3. Алдынгы МТС ларны, совхозларны, колхозларны, бригадаларны, звеноларны, шулай ук алдынгы колхозчыларны, МТС һәм совхоз эшчеләрен һәм авыл хуҗалыгы белгечләрен язып бару өчен өлкә газеталары битләрендә республика почет тактасы кертергә. Республика почет тактасына аларны район советлары башкарма комитетларының, ВКП(б) райкомнарының, МТС һәм совхоз политбүлекләренең тәкъдимнәре буенча язарга.

Почет тактасына кертүгә бәйләнешле булган материалларны карау өчен түбәндәге иптәшләрдән комиссия төзергә: Пазиков (ВКП(б) Өлкә Комитеты секретаре), Шибдин (Татарстан АССР Совнаркомының председатель урынбасары), Перов (ВКП(б) Өлкә Комитетының авыл хуҗалыгы бүлеге мөдире), Әхмиров (ВКП(б) Өлкә Комитетының совхозлар бүлеге мөдире), Хөсәенов (Татарстан АССР ның җир эшләре халык комиссары), Гончаров (Татарстан АССР Наркомземының политсектор начальнигы).

4. Өлкә һәм район газеталарының редакторларын, язгы чәчүгә әзерлек буенча фронт айлыгының барышын киң күләмдә яктыртып торырга мәҗбүр итәргә.

Татарстан АССР Халык Комиссарлары Советы председателе С. ГАФИЯТУЛЛИН.

ВКП(б) ның Татарстан Өлкә Комитеты секретаре А. КОЛЫБАНОВ.

Чәчүлек орлык әзерләүне без ничек оештырабыз

Хәзер безнең райондагы колхозларның 77 проценты чәчүлек орлыклар белән тулысынча тәэмин ителгән.

Булган орлыкларның 80 процентын орлык лабораториясендә бер кат тикшерткән идек инде. Тикшерү, кайбер колхозларда аларның тишелеш һәм дымлылык ягыннан, шулай ук чисталык ягыннан тиешле кондициядә булмавын күрсәтте. Мондый орлыклар бездә 2.800 центнер чамасы бар иде. Без хәзер аларны һәрьяктан тиешле кондициягә җиткерү өчен күп кенә чаралар үткәрәбез. Чисталык ягыннан түбән күрсәткеч биргән орлыкларны кабат чистартабыз. Бу чара яхшы нәтиҗәләр бирә. Бу эш 9 колхозда үткәрелде инде. Дымлылык ягыннан кондициясез орлыклар исә җилләтелә. Тишелеш ягыннан кондициясез орлыкларны эшкәртү буенча да күп кенә чаралар үткәрәбез: «Кишна» колхозының карабодае беренче тикшерүдә бик түбән тишелеш биргән иде. Кабат чистарту һәм җилләтү нәтиҗәсендә, бу карабодайның тишелеп чыгышы 90 процентка күтәрелде. Соңгы вакытта орлыкларның тишелеп чыгышын күтәрү өчен академик Лысенко методын да куллана башладык.

ВКП(б) Өлкә Комитетының IX нчы пленумы чәчүлек орлык әзерләү буенча конкрет күрсәтмәләр бирде һәм колхозларны орлык белән тәэмин итүдә урындагы барлык мөмкинлекләрдән файдаланырга тәкъдим итте. Без пленумның бу күрсәтмәсен тормышка ашыру буенча берникадәр эш үткәрдек һәм беренче нәтиҗәләргә дә ирештек. Бу мәсьәләдә колхозларның һәм колхозчыларның зур инициатива күрсәтүләрен әйтергә кирәк. Мисал өчен Чапаев исемендәге колхозны алыйк. Бу колхозда орлык җитешми. ВКП(б) Өлкә Комитеты пленумыннан соң колхозчылар бу мәсьәләне тикшерү өчен махсус җыелыш үткәрделәр. Бу җыелышта колхозчы Низам иптәш Мифтахов мондый тәкъдим кертте: безнең һәрберебездә бәрәңге быел бик күп. Җитешми торган орлыкларга алмашып алу өчен үз хуҗалыкларыбыздан колхозыбызга бәрәңге биреп тора алабыз, диде.

Колхозчылар бу тәкъдимне алкышлап каршы алдылар. Иптәш Мифтахов шул ук җыелышта колхозга 120 килограмм бәрәңге бирәчәген әйтте.

Чапаев исемендәге колхоздан үрнәк алып бу чара районыбызның башка колхозларында да үткәрелә. Соңгы берничә көн эчендә генә дә шул юл белән 4.000 поттан артык бәрәңге җыелды.

ВКП(б) Өлкә Комитеты пленумының чәчү орлыклары әзерләүгә карата биргән күрсәтмәсен тормышка ашыру нәтиҗәсендә без районыбыздагы чәчүлек орлык фондын 13 процентка үстерүгә ирештек.

С. НАЗИРОВ.

Дөбъяз район советы башкарма комитеты председателе.

КЫЗЫЛ АРМИЯ ФОНДЫНА

Иске Пукшинер авылы, «Авангард» колхозы (Чепья районы) члennары колхозның гомуми фондыннан Кызыл Армия фондына 50 центнер ашлык тапшырырга карар бирделәр.

Г. ГАЛИӘКБЕРОВ.

СВОДКА

ТАТАРСТАН АССР МТС ЛАРЫНДА ТРАКТОРЛАРГА РЕМОНТНЫҢ БАРЫШЫ ТУРЫНДА

1943 нче ЕЛНЫҢ 1 нче МАРТЫНА
(ПЛАНГА КАРАТА ПРОЦЕНТЛАРДА)

МТС лар	Үтәлеш	МТС лар	Үтәлеш	МТС лар	Үтәлеш	МТС лар	Үтәлеш
1. Мөслим	100,0	29. Чистай	80,4	57. Каргалы	63,3	84. Питрәч	51,1
2. Чокалы	100,0	30. Олы Кариле	80,0	58. Куйбышев	63,2	85. Морт	51,0
3. Актаныш	100,0	31. Чыбыклы	77,8	59. Баулы	63,0	86. Макыл	50,9
4. Бөгелмә	100,0	32. Иске Тимошкино	77,2	60. Беренче Май	62,7	87. Майдан	50,0
5. Нөркәй	100,0	33. Димитров	77,1	61. Рождественский	62,5	88. Кама тамагы	50,0
6. Алга	100,0	34. Норлат	76,2	62. Кәкре елга	62,3	89. Карамалы	49,1
7. Тымытык	100,0	35. Мәлки	76,0	63. Чалпы	62,2	90. Әхмәт	49,0
8. Алабуга	100,0	36. Поповка	75,6	64. Маткавыш	62,1	91. Казанбаш	48,5
9. Тирсә	100,0	37. Кызыл йолдыз	75,0	65. Буденный	61,4	92. Үзәк	47,1
10. Ишеево	100,0	38. Аксубай	75,0	66. Тәкәнеш	60,4	93. Балык бистәсе	46,0
11. Чүпрәле	100,0	39. Чаллы	74,5	67. Ютазы	60,0	94. Мамадыш	45,2
12. Дөбъяз	100,0	40. Кузайкино	74,5	68. Зирекле	59,6	95. Тат. Ялтан	43,9
13. Саба	96,0	41. Б. Матак	74,5	69. Әлки	59,5	96 Иске Писмән	43,3
14. Янилъ	95,5	42. Акташ	74,1	70. Солтан	58,8	97. Тат. Ходяш	41,7
15. Юртыш	89,3	43. Бондюг	73,3	71. Мөслим (Чистай)	58,8	98. Трехозерский	39,6
16. Октябрь	87,9	44. Кукмара	73,2	72. Алексеевский	58,7	99. Чишмә	39,4
17. Мөрәле	87,2	45. Исәнбай	73,0	73. Ромадан	57,4	100. Кузнечиха	38,1
18. Дәүләки	87,0	46. Калинин	72,0	74. Черемуховский	57,4	101. Чиябаш	36,5
19. Сарман	86,8	47. Кызыл Чапчак	71,4	75. Буа	57,4	102. Ключи	34,5
20. Кадряк	86,5	48. Тәтеш	70,8	76. Столбище	57,4	103. Әлки	32,1
21. Тархан	83,6	49. Әтнә	68,0	77. Иске Чишмә	56,8	104. Зур Полянә	31,6
22. Юдино	83,3	50. Шөгер	67,9	78. Салман	55,3	105. Биектау	31,2
23. Чүрибураш	83,0	51. Балтач	67,3	79. Константиновка	53,8	106. Кошкино	28,3
24. Соколка	82,4	52. Яңа Чишмә	66,7	80. Кызыл юл	53,3		
25. Т. Тамак	82,1	53. Әлмәт	66,7	81. Биләр	52,4		
26. Заинский	81,0	54. Кичү	66,7	82. Минзәлә	52,1		
27. Азки	81,0	55. Теләче	65,3	83. Арча	51,2		
28. Зөя	81,0	56. Тельман	63,9				

БАРЛЫГЫ: 66,9

1943 нче елның 25 нче февраленә 65,0

Совет Информбюросыннан

4 нче МАРТТАГЫ ИРТӘНГЕ БЕЛДЕРҮ

4 нче мартка каршы төндә безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә һөҗүм сугышлары алып бардылар.

* * *

Безнең гаскәрләр, Ржев шәһәрен алганнан соң, сугыша-сугыша көньяк-көнбатышка таба алга бардылар. Немецларның пехотасы һәм танклары, безнең гаскәрләрнең һөҗүмен тоткарларга һәм яңа оборона чикләрендә нығып урнашырга маташып, берничә тапкыр контратака ясадылар. Гитлерчыларның барлык контратакалары кире кайтарылдылар. Безнең частьлар халык яши торган 11 пунктны алдылар. Бу пунктларның берсе өчен булган сугышта гына да 2 артиллерия һәм 2 миномет батареясы, бер сугыш припаслары склады һәм 200 мичкәдән артык ягулык кулга төшерелде.

* * *

Ростов-Доннан көнбатыштарак Н-че часть сугышчылары дошманның ныгытылган позицияләрен алдылар һәм 3 орудие, 2 миномет, 50 винтовка, 6 пулемет һәм бер радиостанция кулга төшерделәр. Икенче бер участокта дошманның контратакасы кире кайтарылды. Нәтиҗәдә 200 гә якын гитлерчы кырып ташланды.

* * *

Ворошиловградтан көньяк-көнбатыштарак Н-че часть подразделениеләре халык яши торган бер пункт өчен булган сугышта немецларның бер рота пехотасын тар-мар иттеләр һәм 2 танкысын сафтан чыгардылар. Танкка каршы ата торган 3 орудие, 5 пулемет, 2 миномет һәм сугыш припаслары төялгән 11 автомашина кулга төшерелде.

* * *

Харьковтан төньяк - көнбатыштарак Н-че берләшмә частьлары немецларның 20 танк ярдәме белән хәрәкәт иткән пехотасының контратакасын кире кайтардылар. Сугыш нәтиҗәсендә дошманның 10 танкысы зарарланды һәм яндырылды, 200 гә якын гитлерчы юк ителде. Пленныйлар алынды.

* * *

Льгов районында Н-че берләшмә частьлары һөҗүм сугышлары алып бардылар. Бер участокта безнең подразделениеләр халык яши торган бер пунктны алдылар. Немецлар контратака ясадылар һәм бу пунктка яңадан бәреп керделәр. Совет сугышчылары, дошманга нығып урнашырга ирек бирмичә, контрудар ясап, гитлерчыларны аударып ташладылар. Һәм, аларны куып барып, 300 гә якын дошман солдатларын һәм офицерларын юк иттеләр.

* * *

Кубаньда безнең гаскәрләр һөҗүм сугышлары алып бардылар һәм дошманның берничә терәк пунктларын алдылар. Н-че часть сугышчылары, сугыш нәтиҗәсендә, немецларның 3 орудиесен, 14 пулеметын, 11 автомашинасын һәм бер радиостанциясен кулга төшерделәр. Пленныйлар алынды.

* * *

Орел өлкәсенең бер районында хәрәкәт итүче партизаннар отряды 18 нче февральдә кинәт немецлар гарнизонына һөҗүм иткән. Ике арада башланып киткән сугышта совет патриотлары 90 гитлерчыны кырганнар. Икенче отрядның партизаннары немецларның бер хәрби эшелонын юлдан чыгарганнар. Һәлакәт нәтиҗәсендә бер паровоз, 2 вагон, орудиеләр һәм автомашиналар төялгән 5 платформа җимерелгән, 17 гитлерчы үтерелгән һәм 35 гитлерчы яралангән.

* * *

Орел партизаннарының бер группасы, шоссе юлында засадада торып, немецларның бер автоколоннасына аткан. Мылтык-пулемет уты белән 40 солдат үтерелгән. Партизаннар ике станоклы пулемет, 10 кул пулеметы, 4 автомат һәм 50 винтовка кулга төшергәннәр.

* * *

3 нче мартта Берлин радиосы түбәндәге хәбәрне тапшырды: «Империя министры доктор Геббельс Великие Луки шәһәренең героик гарнизонының берничә көнгә Берлинга килгән вәкилләрен кабул итте. Кабул вакытында бу сугышларда катнашучылар шәһәрнең эчендә крепостьны саклау ничек булганлыкны сөйләделәр». Мәгълүм ки, совет гаскәрләре Великие Луки шәһәренең немецлар гарнизонын тулысына юк иткәннәр иде, ә аның кызганыч калдыклары шәһәр коменданты подполковник фон Засс белән берлектә плен алынганнар иде. Великие Луки гарнизонының плен алынган солдатлары һәм офицерлары хәзер совет лагерьларында торалар һәм, билгеле, кабул итүдә булулары мөмкин түгел. Шулай булгач, ялганлау докторы Геббельс кемнәрне кабул иткән соң? Мәетләрне түгелме икән? Башлап җибәрү генә авыррак. Хәзер инде Геббельска Сталинградтан, Чертководан, Касторноедан һәм немец гарнизоннары чолгап алынып кырып бетерелгән башка күп урыннардан килгән вәкилләрне кабул итүне генә оештырырга кала.

Немецлар Франция Пиренеен оккупацияләгәннәр

ЛОНДОН, 2 март. (ТАСС). Рейтер агентлыгы Женевадан алып хәбәр итә:— Монда алынган хәбәрләргә караганда, немецлар Пиренейнең Франциядәге районын 60 миль эчкәрегә таба оккупацияләгәннәр. Оккупацияне барлыгы 20.000 чамасы кешедән торган Германия гаскәрләре һәм гестапо отрядлары үткәргән. Әйтүләренә караганда, оккупация Францияне Швейцариядән аерган кебек Испаниядән дә бөтенләй аеру өчен үткәрелгән.

РИББЕНТРОПНЫҢ РИМГА БАРУЫНА КАРАТА

ЛОНДОН. АФИ агентлыгы, Риббентропның Римга баруына комментарийлар биреп, дипломатия даирәләренең фикеренчә, Риббентропка үзенең хәлсезләнеп баручы итальян союзнигын чыбыркылау эше тапшырылган, дип яза. «Ивнинг стард» газетасының фикеренчә, Риббентроп Италиядән Германиягә 500.000 эшче җибәрүне, Германия карамагына 15 яңа дивизия бирүне һәм Урта диңгездә хәрби-диңгез операцияләрен көчәйтүне таләп иткән. Шулай ук Италиягә, илдә Германиягә каршы булган настроениеләрне тагын да көчлерәк чаралар белән бастырырга тәкъдим ителгән. Башка күзәтүчеләрнең әйтүенчә, Гитлер тоталь мобилизацияне үзенең барлык союзникларына да карата кулланырга карар биргән.

Берлинга ясалган һөҗүмнең нәтиҗәләре

ЖЕНЕВА, 2 март. (ТАСС). Гитлерчыларның Трансоцеан агентлыгының хәбәр итүенә караганда, 2 нче мартка каршы төндә Англия самолетлары Берлинга зур һөҗүм ясаганнар. Һөҗүм нәтиҗәсендә шактый күп зыян китерелгән. Шәһәрнең күп кенә кварталларында зур җимерелүләр бар.

Венгриядә дәүләт переворогы әзерләү турындагы эш буенча хөкем карары

ИСТАМБУЛ, 3 март. (ТАСС). Венгрия матбугатының хәбәр итүенә караганда, Коложвар шәһәрендә 63 венгерның эше буенча суд тәмам булган. Бу кешеләр Венгриядә дәүләт переворогы әзерләүдә гаепләнәләр. Прокурор үзенең гаепләү речендә, фаш ителгән оешмада 1.200 кеше булганлыкны һәм шулардан 548 кешенең кулга алынганлыгын белдергән. Гаепләнүчеләр барысы да каторга эшләренә хөкем ителгәннәр.

БЕЛДЕРҮ

Бүген, 19 сәгатьтә ВКП(б) шәһәр комитетының Партия мәгарифе йортында «Сугыш турында Маркс—Ленин тәгълиматы» дигән темага үзлекләреннән укучылар өчен групповой консультация үткәрелә. Консультант—иптәш Г. Л. Зельманова.

Җаваплы редактор **И. ҮЗБЕКОВ.**

4 нче МАРТТАГЫ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

4 нче мартта Ржевтан көнбатыштарак безнең гаскәрләр Оленино шәһәрен һәм тимер юл станциясен, шулай ук зур тимер юл станциясе Чертолиноны алдылар.

Орел өлкәсендә безнең гаскәрләр, каты сугыштан соң, Севск шәһәрен алдылар.

Курск өлкәсендә безнең гаскәрләр, кискен атака нәтиҗәсендә, Суджа шәһәрен һәм тимер юл станциясен алдылар.

Фронтның башка участокларында безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә һөҗүм сугышлары алып бардылар.

* * *

Ржевтан көнбатыштарак безнең гаскәрләр, һөҗүмне җәелдерүне дәвам иттереп, Оленино шәһәрен һәм тимер юл станциясен, Чертолино һәм Манчалово тимер юл станцияләрен алдылар. Манчалово станциясе өчен булган сугышта Н-че часть сугышчылары 400 гә якын немец солдатларын һәм офицерларын юк иттеләр, 6 паровоз, 3 тимер юл составы һәм шуның өстенә бик күп вагоннар кулга төшерделәр. Ржевтан көньяк-көнбатыштарак Н-че берләшмә частьлары, дошманның каршылык күрсәтүен җиңеп, алга таба бардылар. Халык яши торган уннарча пунктлар немец-фашист басып алучылардан азат ителде. Бик күп трофейлар кулга төшерелде. Аларның саны алына.

* * *

Ростов-Доннан көнбатыштарак безнең гаскәрләр каты каршылык күрсәтүче дошманга каршы һөҗүм сугышлары алып бардылар. Немецлар үзләренең ныгытылган, югалткан позицияләрен кайтарырга маташып карадылар һәм берничә контратака ясадылар. Гитлерчылар, берниндн дә нәтиҗәгә ирешә алмыйча, безнең позицияләр алдында 600 дән артык үле гәүдәләрен һәм сафтан чыгарылган 4 танкларын калдырып, чигенделәр.

* * *

Ворошиловградтан көньяк-көнбатыштарак Н-че берләшмә частьлары дошманга каршы сугышта бер самоход орудие, 5 пулемет, 3 миномет һәм бер радиостанция кулга төшерделәр. Икенче бер участокта безнең подразделениеләр, дошманның контратакасын кире кайтарып, бер ротага якын гитлерчыларны юк иттеләр һәм немецларның 3 танкысын яндырдылар.

* * *

Харьковтан төньяк-көнбатыштарак безнең гаскәрләр һөҗүмне дәвам иттерделәр. Н-че часть дошманны халык яши торган бер зур пункттан бәреп чыгарды һәм бер сугыш припаслары склады, бер инженерлык милекләре склады һәм күп кораллар кулга төшерде. Коралларның саны алына.

* * *

Льгов-Дмитриев-Льговский районында безнең гаскәрләр һөҗүмне дәвам иттерделәр һәм халык яши торган берничә пунктны алдылар. Льгов шәһәре өчен булган сугышларда соңгы 4 көн эчендә 6.000 нән артык немец солдатлары һәм офицерлары юк ителде. 300 дән артык гитлерчы плен алынды. Өстәмә саннар буенча, Льговта дошманның 4 танкысы, 20 орудиесе, 75 минометы, 66 пулеметы, 150 автоматы, 700 дән артык винтовкасы һәм башка трофейлар кулга төшерелде. Икенче бер участокта безнең частьлар халык яши торган ике зур пункт өчен каты сугышлар алып бардылар. Кичкә таба безнең сугышчылар бу пунктларны алдылар. Трофейлар кулга төшерелде. Шулар арасында 2 орудие, 11 миномет, 20 пулемет, 72 автомат, 370 винтовка, 2.500 мина, 17.000 патрон һәм 2 сугыш припаслары склады бар. Халык яши торган пунктларга килү юлларында һәм аларның урамнарында гитлерчыларның 800 ләп үле гәүдәләре табылды. Берничә дистә немец солдатлары плен алынды.

* * *

Төньяк-Көнбатыш фронтта бер участокта безнең частьлар халык яши торган ике пунктны алдылар. Каршылык күрсәткән немец гарнизоннары тулысынча юк ителде. Икенче бер участокта Н-че часть немецларны ныгытылган позицияләрдән бәреп чыгарды. Дошман, ашыгыч рәвештә чигенеп, сугыш кырында үзенең яралы солдатларын һәм техникасын ташлап калдырды.

* * *

Витебск өлкәсенең бер районында хәрәкәт итүче партизаннар отряды немецларның бер аэродромына һөҗүм иткән. Партизаннарның махсус билгеләнгән группасы гитлерчыларның аэродром командасына каршы сугышкан арада отрядның төп көчләре очу площадкасына бәреп кергәннәр һәм анда 4 самолетны юк иткәннәр. Берничә көннән бу отряд немецларның сугыш припаслары һәм киемнәр төялгән бер хәрби эшелонын юлдан чыгарган. Совет патриотлары бик күп сугыш припаслары һәм киемнәр кулга төшергәннәр. Җимерелгән эшелоннан алып китәргә мөмкин булмаган барлык әйберләрне партизаннар яндырганнар.

* * *

Норвегия патриотлары, репрессияләргә дә карамастан, немец-фашист басып алучыларга каршы көннән-көн көрәш алып баралар. Берген районында бер группа кораллы норвегиялеләр немецларның бер автоколоннасына атканнар. Осло шәһәрендә ун көн эчендә генә дә 8 немец солдаты һәм офицеры үтерелгән. Тронхейм районында Норвегия партизаннары прожектор установкасын һәм аны саклаучы гитлерчыларны юк иткәннәр.

ХРОНИКА

Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы указы белән иптәш Бәдретдин Зәятдин улы Мулюков Татарстан АССР Халык Комиссарлары Советы Председателенең урынбасары итеп билгеләнде:

Спорт яңалыклары

◇ Казанда чаңгы буенча шәһәр беренчелеге өчен ярышлар ике көн дәвам итте. Ярышларда «Динамо» командасы беренче урынга чыкты. Ирләр арасында 10 һәм 20 километрга чаңгы белән баруда спорт мастеры иптәш Соколов, хатын-кызлар арасында 5 километрга баруда спорт мастеры иптәш Курдош («Пищевик») һәм 10 километрга баруда иптәш Дубинина («Динамо») 1943 нче елга чемпион исемен яулап алдылар.

◇ Физкультура һәм спорт комитеты Казан пионерлар йортында балалар өчен спорт мәктәбе ачты. Мәктәпнең гимнастика, фехтование һәм бокс бүлекләре бар.

◇ Кызыл Армиянең 25 еллыгы хөрмәтенә баскетбол буенча блиц-турнир үткәрелгән иде. «Зенит» командасы блиц-турнирда беренче урынга чыкты. «Динамо» командасы икенче урынны алды.

◇ Казан шәһәренең чаңгычылар командасы Бөтенсоюз ярышларында катнашу өчен Свердловск шәһәренә барырга әзерләнә. Командага спорт мастерларыннан Соколов, Дубинина, Курдош һәм шәһәрнең иң яхшы чаңгычыларыннан Афанасьев, Фатеев, Шишкин, Чукаева, Сурков һәм Куделькина иптәшләр керделәр.

◇ 8 нче март көне хөрмәтенә шәһәрдә баскетбол буенча хатын-кыз командаларының блиц-турниры үткәрелә. Блиц-турнирда «Динамо», «Зенит», «Спартак» спорт җәмгыятьләренең командалары катнашачак.

◇ Шушы көннәрдә Бауман районы катогында хоккей буенча блиц-турнир үткәрелә. Анда ирләрдән төзелгән берничә команда очрашачак.

Театрларда һәм киноларда

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры. Бүген — „*Хуҗа Насретдин*“, 6 нчы мартта—„*Печән өстендәге эт*“.

Зур драма театры. Бүген — „*Маскарад*“, 6 нчы мартта — „*Нашествие*“.

Яшь тамашачылар театры. Бүген Кызыл Армиянең 25 еллыгына багышланган *спектакль - концерт*. Кич 7 сәгатьтә башлана.

Дәүләт циркы. Бүген зур цирк тамашасы һәм французча көрәш ярышлары. Кич 8 сәгатьтә башлана.

„Электро“ — „*Җиңелмәслекләр*“.

„Унион“ көндез — „*Юденичны тар-мар итү*“, кич—„*Таҗикстан улы*“.

„Чаткы“ — „*Тимер һәм аның командасы*“, кич — „*Сөекле кыз*“.

„Кызыл йолдыз“ — „*Котовский*“.

„Пионер“ көндез һәм кич—„*Өч мушкетер*“.

Редакциянең телефон номерлары: җаваплы редактор, редактор урынбасары— АТС 76—29, секретарь, промышленность - транспорт һәм авыл хуҗалыгы бүлеге— АТС 79—29. типография 36—60.

ПФ1071 «КРАСНАЯ ТАТАРИЯ» һәм «КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН» издательствосының АЛЕКСАНДРОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТИПОГРАФИЯСЕ № Заказ 357